СОВЕТ ТУБЫЛГЫТАУСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423181, РТ, Новошешминский район,
село Тубылгы Тау, ул.Молодежная, д.73,

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТУБЫЛГЫ ТАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
423181,ТР, Яңа Чишмә районы,
Тубылгы Тау авылы, Яшьләр урамы,
73

тел.:(8-84348)3-82-58,факс:(8-84348)3-82-44,Tub.Nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы
Тубылгы Тау авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2023 елның 24 нче апреле № 30-107

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге Советы 19.11.2012 18-46 номерлы «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Тубылгытау авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Җир кодексы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Тубылгытау авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге Советының 19.11.2012 18-46 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә (19.12.2016 19-49 номерлы, 21.01.2021 7-17 номерлы карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 30 статьяның 1.1 өлешенең «Җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалануның төп төрләре» икенче абзацына түбәндәге эчтәлекле пунктчалар өстәргә:

«- индивидуаль торак төзелеше өчен;
- шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен (йорт янындагы җир кишәрлеге);
- яшелчәчелек алып бару өчен;
- коммуналь хезмәт күрсәтү;
- коммуналь хезмәтләр күрсәтү;
- гараж;
- хуҗалык сарае;
- базарлар;
- кибетләр;
склад бүлмәләре.»

1.2. 34 статьяның 2.1 өлешенең «Җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалануның төп төрләре» икенче абзацына түбәндәге эчтәлекле пунктчалар өстәргә:

«- авыл хуҗалыгын алып бару өчен, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге объектларны алып бару өчен;

- Су башнялары.»

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда: http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Яңа Чишмә муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында: http://novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге Советының законлылык, экология, җирдән файдалану, торак-коммуналь хуҗалык һәм территорияне төзекләндерү мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Тубылгы Тау авыл җирлеге башлыгы

Ф.Ф. Исмәгыйлев